| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

Зур Тигәнәле авылы

08.10.2019 № 130

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлегендә**
**муниципаль хезмәт турындагы**
**Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, муниципаль хезмәт турындагы 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына, «Коррупциягә каршы тору турында " 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә,таянып

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегенең 2018 елның 25 июнендәге 93 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә.

түбәндәге эчтәлекле 11.3 пунктын өстәргә:

«11.3. Гражданин муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органының рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларын, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органының рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларын, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлык мөнәсәбәтләрендә (ата –аналары, ир белән хатын, балалары, бертуганнары, хатынының, я ирнең бертуганнары,

ата-аналары, балалары, балаларының тормыш иптәшләре) булса, вазыйфага билгеләнә дә, били дә алмый.

Җирле үзидарә органында, җирлек сайлау комиссиясе аппаратында, җитәкче булучы муниципаль хезмәткәр, әлеге вазыйфаны биләгән чорда, җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, җирлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.»;

12.1 пунктының 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

2) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарәдә катнашудан тыш); җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән һөнәр берлеге органы, шул исәптән, түләүсез нигездә идарәдә катнашу; бүтән иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек хуҗалары ширкәтләренең съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашу; күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән һәм һөнәри берлек органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органыннан тыш) белән идарә итүдә түләүсез катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән керү, ул муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә алынган), муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль милектә булган оешманы яки идарә итүне гамәлгә куючы (устав капиталында катнашу өлешләре) вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә кую тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючы (Акционер) оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш; федераль законнарда каралган башка очракларда»;

12.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«12.3 Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданин муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң ике ел эчендә хезмәт килешүе шартларында оешмада эш урынын биләп торырга, һәм (яки) әлеге оешмада эшне башкарырга (хезмәт күрсәтергә) бер ай эчендә бәясе 100 мең сумнан артык булган граждан-хокукый шартнамә шартларында (граждан-хокукый шартнамәләр), муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре муниципаль хезмәткәрнең вазифа (хезмәт) бурычларына кергән булса, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча тиешле комиссия ризалыгы белән.»;

16.3 пунктының 6 нчы пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

“6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ формасында;”

26.9 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«26.9 Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 32 статьясында каралган түләтүләр, хезмәткәрнең авыру вакытын, отпускта булу вакытын исәпкә алмыйча, муниципаль хезмәткәр тарафыннан хокук бозу кылган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, шулай ук хезмәткәрләрнең вәкиллекле органы фикерен исәпкә алырга кирәк булган вакытны исәпкә алмыйча кулланыла. Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән, бурычларны үтәмәгән өчен дисциплинар җәза коррупциячел хокук бозу кылган көннән соң өч елдан да соңга калып кулланыла алмый.».

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 23 гыйнварындагы 112 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Зур Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.Ж.Әхмәтҗанов**